СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.04.2016 Алабуга шәһәре №61

Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кабул итү турында» 2016 елның 11 февралендәге 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кабул итү турында» 2016 елның 11 февралендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.6 пунктындагы 1.6.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6.7. муниципаль мөлкәтне арендага, түләүсез файдалануга һәм милекче кушуы буенча концессиягә тапшыруны оештыру;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе Г.Е. Емельянов